ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.12.2017 Балык Бистәсе штп. № 263пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында социаль килешү нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәме, шул исәптән социаль килешү нигезендә күрсәтү турында” 2014 елның 2 сентябрендәге 635 номерлы карарына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында социаль килешү нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия төзергә.

2.Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында социаль килешү нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия турында Нигезләмәне;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында социаль килешү нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия составын.

3.Түбәндәгеләрнең көчен югалтуын таныргa:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының “Социаль килешү нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү буенча ведомствоара комиссия турында” 2011 елның 28 февралендәге 34пи номерлы карары;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының “Социаль килешү нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү буенча яңа составтагы ведомствоара комиссияне раслау турында” 2012 елның 9 августындагы 212пи номерлы карары;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының “Социаль килешү нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү буенча яңа составтагы ведомствоара комиссияне раслау турында” 2015 елның 19 гыйнварындагы 36пи номерлы карары.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Җитәкче Р.Х. Хабибуллин

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2017елның 14 декабрендәге
263пи номерлы карары
белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында социаль килешү нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия турында Нигезләмә**

1.Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында социаль килешү нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия (алга таба – ведомствоара комиссия) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәме, шул исәптән социаль килешү нигезендә күрсәтү турында” 2014 елның 2 сентябрендәге 635 номерлы карарына ярашлы рәвештә төзелде.

1.2.Ведомствоара комиссия Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән төзелә.

1.3. Ведомствоара комиссия үзенең эшендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының башка норматив-хокукый актларына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында социаль килешү нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия турындагы әлеге Нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) таянып эш итә.

2. Ведомствоара комиссиянең функцияләре һәм вәкаләтләре

2.1.Комиссия Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Балык Бистәсе муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге (алга таба – социаль яклау бүлеге) тәкъдим иткән социаль килешү нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү буенча гариза һәм документларны карый, гаиләләрнең (ялгыз көн күрүче гражданнарның) социаль адаптациясе программаларын раслау турында карар кабул итә.

2.2.Мөрәҗәгать итүче тапшырган мәгълүматларга өстәмә тикшерү үткәрү зарурлыгы булганда, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 1.3 пунктында күрсәтелгән хокукый актларда билгеләнгән очракларда ведомствоара комиссия

нәтиҗәләре акт белән рәсмиләштерелә торган комиссия тикшерүен үткәрүне билгели.

## 3. Ведомствоара комиссиянең хокуклары

Ведомствоара комиссия хокуклы:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының тармак (функциональ) органнарыннан, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының бүтән җирле үзидарә органнарыннан, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль учреждениеләреннән ведомствоара комиссия эшчәнлегенә кагылган сораулар буенча мәгълүмат (материаллар) алырга;

билгеләнгән тәртиптә башкарма хакимиятнең федераль органнарының Татарстан Республикасындагы территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарыннан, шулай ук оешма, предприятие, учреждениеләрдән ведомствоара комиссиянең үзенең эш йөртергә хакы булган өлкә чикләрендәге мәсьәләләр буенча мәгълүматлар соратып алырга;

ведомствоара комиссия эшендә катнашу өчен килештерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарының, башкарма хакимиятнең федераль органнарының Татарстан Республикасындагы территориаль органнарының, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларын һәм белгечләрен, шулай ук район территориясендә урнашкан предприятие, учреждение һәм оешмалар вәкилләрен тартырга.

## 4. Ведомствоара комиссиянең эшләү тәртибе

4.1. Ведомствоара комиссиянең утырышлары зарурлык булганда үткәрелә.

4.2. Ведомствоара комиссия эшенә җитәкчелек итүне аның рәисе гамәлгә ашыра. Рәис булмаганда ведомствоара комиссия утырышын аның урынбасары уздыра.

4.3.Әгәр утырышта ведомствоара комиссия әгъзаларының яртысыннан ким булмаган өлеше катнашса, комиссия утырышы вәкаләтле санала. Ведомствоара комиссия әгъзалары утырышларда алмаштыруга хокуксыз рәвештә катнашалар. Ведомствоара комиссия әгъзасы утырышта катнаша алмаган очракта карала торган мәсьәләләр буенча ул үз фикерен алдан язмача рәвештә ирештерергә хокуклы.

Карар утырышта катнашучы ведомствоара комиссия әгъзалары саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булган очракта ведомствоара комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч була. Ведомствоара комиссия карары утырышта катнашучы барлык комиссия әгъзаларының имзасы салынып беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә.

4.4. Гаиләнең (ялгыз көн күрүче гражданның) социаль адаптациясе программасын раслау турында карар ведомствоара комиссия тарафыннан

социаль яклау бүлеге гаиләнең (ялгыз көн күрүче гражданның) социаль адаптациясе программасын җибәргән көннән ике эш көне эчендә кабул ителә.

4.5. Ведомствоара комиссия сәркатибе комиссия утырышы беркетмәсен 2 (ике) нөсхәдә әзерләүне гамәлгә ашыра.

4.6.Ведомствоара комиссия карарына мөрәҗәгать итүче законда каралган тәртиптә шикаять белдерә ала.

4.7.Ведомствоара комиссия карары дәүләт социаль ярдәме билгеләү (яки билгеләүне кире кагу) өчен нигез булып тора.

4.8. Ведомствоара комиссия эшчәнлеген оештыру-техник һәм мәгълүмати тәэмин итүне социаль яклау бүлеге (килештерү буенча) гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2017елның 14 декабрендәге
263пи номерлы карары
белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында социаль килешү нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия составы**

1.Хәбибуллин Р.Х. – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе;

2.Талалаева М.Р. – Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Балык Бистәсендәге социаль яклау бүлеге башлыгы, комиссия рәисе урынбасары (килештерү буенча);

3.Нуриәхмәтова Г.Н. – КЦСОН “Доверие-Ышаныч” гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм бүлекчәсе мөдире, комиссия сәркатибе (килештерү буенча);

Комиссия әгъзалары:

4.Гарифуллина Р.А. – Балык Бистәсе районының “Халыкның мәшгульлек үзәге” ДКУ се директоры (килештерү буенча);

5.Китаев М.Р. – “Балык Бистәсе үзәк район хастаханәсе” ДАССУсенең баш табибы (килештерү буенча);

6.Садиков И.М. – “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге” МКУ се башлыгы;

7.Баһаутдинова Г.М. – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек буенча бүлек башлыгы.